**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫЛАЕШМУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫАЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**422613 н.п. им. «25 Октября»тел: 8-(84378) -3-54-22факс: 8-(84378) -3-54-22**

**2020елның 07 октябре** **9 номер**

# КАРАР

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2014 елның 14 декабрендәге 15 номерлы
Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль
районының Александровка авыл җирлеге
советы карарына өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 декабрендәге 15 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александровка авыл җирлеге советы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә::

а) 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга (ата-аналарга, уллыкка алучыларга, опекуннарга, попечительләргә), шулай ук әлеге затларның 18 яшькә кадәрге балаларына салым ташламасы түбәндәге салым салу объектларына карата бирелә:

1) квартира, фатирның яисә бүлмәнең бер өлеше;

2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;

гараж яисә машина урыны.

Салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салу объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым объектына карата салым түләүче тарафыннан тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламасына хокуклы затлар салым органына ташламалар бирү турында гариза, шулай ук салым ташламасына хокукны раслаучы документлар тапшыралар.

Уведомление о выбранных объектах налогообложения, в отношении которых предоставляется налоговая льгота, представляется налогоплательщиком в налоговый орган по своему выбору не позднее 31 декабря года, являющегося налоговым периодом, начиная с которого в отношении указанных объектов применяется налоговая льгота.»

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында htth://pravo.tatarstan.ru, веб-адресы буенча Интернет Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының htth://laishevo.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александровка авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александровка авыл җирлеге Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Александровка**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **И.А.Бандурова**